**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

***БУА РАЙОН СОВЕТЫ***

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

***БУИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ***

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

16 сентябрь 2013ел № 10-34

«Буа районы Советының 2009 елның 29 декабрендәге
3-40 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль
районының мунипаль мөлкәтен хосусыйлаштыру
тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү хакында»

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 13 статьясы, 2 өлеше (2011 елның 06 декабрендәге 401-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) «Буа муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә (алга таба Нигезләмә), Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге уставының 88 статьясы нигезендә Буа район Советы карар кабул итте:

1. Буа район Советының 2009 елның 29 декабрендәге 3-40 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

а) 5 бүлектә:

10абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-ышаныч белән идарә итү нәтиҗәләре буенча ачык акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен сату;»;

түбәндәге эчтәлекле 11 абзацны өстәргә:

«-унитар предприятиене килешү чикләнгән җәмгыятьтә үзгәртеп кору.».

б) 8 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмат әлеге федераль законда башкасы каралмаган булса, күрсәтелгән мөлкәтне сату көненә кадәр кимендә утыз көн кала Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (torgi.gov.ru) басылып чыгарга тиеш.».

2. Әлеге карарны район газетасында бастырып чыгарырга һәм Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Буа муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУга (рәисе А.Ф. Әхмәтҗанов) йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа район Советы рәисе А.К. Айзетуллов